ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 17.10.2022 **КАРАР**
1346

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарның гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары хакында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарның гаиләләренә өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарның (алга таба-хәрби хезмәткәрләр) гаиләләрен, ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түбәндәге түләүләрдән азат итәргә:

- Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында туклану, шулай ук баланы карап торган һәм караган өчен;

- Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында мәктәптә тукланганы өчен;

- Алабуга муниципаль районы башкарма хакимияте органнары карамагындагы мәктәпләрдә, мәктәпкәчә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендәге түгәрәкләр һәм секцияләр өчен.

2. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына (Е.Д. Терентьева), «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына (Ю.Р. Шәкүрова), Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы мөдиренә (Р.А. Деготьков) 2022 елның 25 октябренә кадәр, әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтүнең тәртибен эшләргә һәм расларга.

3. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына (Е.Д. Терентьева):

3.1. мәктәпкәчә белем бирү буенча хезмәтләр күрсәтүче мәгариф оешмаларына, чираттан тыш тәртиптә, хәрби хезмәткәрләрнең яшь ярымга җиткән балаларына юллама бирүне тәэмин итәргә;

3.2. Алабуга муниципаль районының мәктәп яны лагерьларына сменалар туплаган саен, чираттан тыш тәртиптә, хәрби хезмәткәрләрнең балаларын җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторы мөдиренә (М.Д. Мәсәлимов):

4.1. Алабуга муниципаль районының һәм Татарстан Республикасының балаларны сәламәтләндерү лагерьларына сменалар туплаган саен, чираттан тыш тәртиптә, хәрби хезмәткәрләрнең балаларын җибәрүне тәэмин итәргә.

4.2. хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларына бушлай психологик ярдәм күрсәтергә;

4.3. волонтерлар көче белән хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә адреслы ярдәм оештырырга.

5. Түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

5.1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спорт үсеше секторы мөдиренә (Р.А. Деготьков) хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларын Алабуга муниципаль районының спорт объектларына абонементлар буенча бушлай йөртүне;

5.2. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына (Ю.Р.Шәкүрова) «Иллюзион» кинотеатрына һәм шәһәр мәдәният сараенда узган чараларыга, алдан язылу тәртибе буенча, хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларын бушлай йөртүне.

6. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннәндә тәрбияләнүчеләргә Алабуга муниципаль районының белем бирү оешмаларында ярдәм чараларын финанслауны тәкъдим итәргә.

7. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибына (Р.Р. Сәфәров) Татарстан Республикасы шифаханәләрнә һәм профилакторияләренә заездлар туплаганда, чираттан тыш тәртиптә, хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларын җибәрүне тәкъдим итәргә.

8. Алабуга рйоны һәм Алабуга шәһәре хәрби комиссарына (Н.Н. Битюков) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына, һәр айның 10 нчы числосына кадәр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнар исемлеген булдыруны һәм җибәрүне тәкъдим итәргә.

9. Әлеге карарның гамәлдә булуы Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар (Татарстан Республикасында формалашкан «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнар) тарафыннан хәрби хезмәт үтәү чорына 2022 елның 1 октябреннән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

10. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы белем бирү оешмаларында өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын карау һәм тәрбияләп тору өчен түләүдән азат итү турында» 2022 елның 30 сентябрендәге 1283 номерлы карарын гамәлдән чыгарыга.

11. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA

Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович

Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Л.Ф. Нургаянов



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН